**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**

# Ул минем өчен, ул минем көчем!

2нче жыентык

**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**

## Нефтяник, поэт, донор

«В ПАО «Татнефть» имени В.Д. Шашина трудятся умные, инициативные и творческие люди с широким кругозором и разносторонними интересами.

Творческий нефтяник-это прекрасно. Сегодня мы расскажем про Шибаева Равиля Файзиевича. Он умудряется сочетать работу промышленной безопасности, охраны труда и окружающей среды с выпуском сборников стихотворений, с донорством (в республиканском центре крови г.Казань 2 раза в год сдает, безвозмездно кровь, спасая жизни других людей), является председателем многоквартирного дома (МКД) где решает множество проблем. Его девиз: «Человек – это часть природы, в которой всё взаимосвязано. Поэтому, беречь и охранять ее нам необходимо».

Его стихотворения были опубликованы в 3-х книгах под названием: «Вдохновленные нефтью», «Добывая, бережно сохраняем!» и «Елабуга Татнефть Шибаев». С сыном Алмаз (ученик 7 «Б» класса МАОУ «Полилингвальный образовательный комплекс «Адымнар–Алабуга» ЕМР РТ, директор: Надир Дамирович Курамшин) участвует во всех конкурсах города и ПАО «Татнефть», занимая почетные призовые места. Трудовой стаж в НГДУ «Прикамнефть» около 30 лет. На вопрос как стал нефтяником, с улыбкой отвечает: «родился от знаменитой скважины №15 ЦДНГ-1 Бондюжского месторождения в 3-х километрах, вот и стал нефтяником, другого выбора не было». А если честно, то работа в ПАО «Татнефть» дает уверенность в завтрашнем дне.

Трудовую деятельность начал в ЦДНГ-1 оператором по добыче нефти и газа, 2 разряда. Обслуживал скважины ГЗУ-24 и ГЗУ-16, ГЗУ-16А. Начальником цеха тогда был Васильев Л.Ф., который всегда и в любую погоду мог приехать (а если не было

**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**

дорог даже на лыжах) с проверкой и всегда Равиль встречал его около устья скважины, за работой. Через три года таких проверок, Леонид Филиппович сказал: «Молодец! Видно, что ты старательный парень, такие нам нужны!». Шли годы, за качественное выполнение работ присваивались разряды до высшего – 6 разряда (по разряду можно определить уровень профессионализма нефтяника), потом предложили работать инженером- технологом ЦДНГ-1. Вспоминая о цехе добычи нефти и газа №1 Равиль Файзиевич говорит, что это родной коллектив, как семья.

С благодарностью вспоминает Васильева Л.Ф.; Зиннатуллина Ш.Ш.; Гырдасова В.М.; Гудовских Н.А.; Смирнова Ю.Г.; Туголукова А.А.; Полтанова Д.В.; Юсупова Э.Р.; Евграфова М.Я.; Томилова И.В.; Камаева О.Г. и наставника Филатова А.М.

В 2018 году предложили работу в службе по борьбе с коррозией и охране природы (СБКиОП), инженером. Начальник службы Халиков Рашид Габдулхакович после собеседования показал рабочее место, познакомил с коллегами. И здесь работали профессионалы своего дела, Хаяров С.А. и Осипов М.А. помогали войти в курс дела.

В связи с оптимизацией службу переименовали в отдел транспортировки нефти, газа и воды (ОТНГиВ). Равиля Файзиевича назначили ведущим инженером по защите от коррозий и борьбе с осложнениями. Работал под руководством опытного, грамотного, честного и высокоинтеллектуального человека - Камаева Олега Григорьевича.

В НГДУ «Прикамнефть» работают только смелые, сильные, мужественные, умные люди продолжает беседу Равиль и если я добился чего-то на работе, то это заслуга вышеперечисленных людей, которые были всегда рядом, поддерживали и я им верил, как себе. Спасибо Вам, коллеги!

**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**

С августа 2020 года Равиль Файзиевич работает ведущим специалистом по промышленной безопасности, охране труда и окружающей среды СП «Татнефть-Добыча» ПАО «Татнефть».

*«Нефтяник Прикамья»*
*№4 (45) Апрель 2021 г.*

## Кеше баласы

Табигатьнең матурлыгын күреп,
Килә кинәт каен буласы.
Искән җилгә ботакларны иеп,
Килә сине кочып аласы.

Табигатьнең матурлыгын күреп,
Килә минем кошчык буласы.
Матур итеп, талга кунып сайрап,
Сәлам диеп, бер күз кысасы.

Табигатьнең матурлыгын күреп,
Килеп китә кояш буласы.
Җылы, якты нурларымны сибеп,
Күзләреңә карап аласы.

Табигатьнең матурлыгын күреп,
Килә бары алга барасы.
Кулларыңны кулларыма алып,
Килә бары сөеп карыйсы!

Табигатьнең матурлыгын күреп,
Гашыйк булдым сиңа ахрысы.
Хыяллардан чыккач искә төшә,
Мин бит бары кеше баласы.

## Ел фасылы

Сәлам сиңа язгы Алабуга,
Урамыңнан гөрләвекләр ага.
Күңел тула матурлыкны күреп,
Кояш көлә, яшәргә көч биреп.

Сәлам сиңа җәйге Алабуга,
Ел фасылы тәэсир итә сиңа.
Күмеләсең син яшеллеккә,
Омтыласың тик гүзәллеккә.

Сәлам сиңа көзге Алабуга,
Көз житкәч тә үзең чибәр әле.
Моңсуланма жәйләр үтте диеп,
Яшик әле синдә жырлап, биеп.

Сәлам сиңа кышкы Алабуга,
Әйләндең син тагын ак калага.
Аккошлардан бердә ким түгел,
Охшап калдың безнең башкалага!

## Фикер

Фикернең чуалган чагында,
Көннең яктылыгы күренми.
Кояш чыкмавына карамастан,
Аларны чишәм көндә, иренми.

Чишми булмый, буталган фикерне,
Жиңүләргә килә барасы.
Чакрымнарны сизми генә үтәм,
Алабуга-Әлмәт арасын.

Авыр диеп, артка чигенергә,
Вакытым да, теләгем дә юк.
Бары алга барам, юлны ярып,
Эштән кайтам күпчак бик арып.

Бар да яхшы булыр,
Бүтән төрле мөмкин түгелдер.
Раббым, зинһар, таңнар ату белән,
Яхшы хәбәр белән сөендер!

## Яз гына гаепле икән

Уянып киттем бүген яз исенә,
Төштең шулчак үзең исемә.
Яз көнендә танышканым синең белән,
Бүгенгедәй әле исемдә.

Сайрый иде кошлар иртә таңнан,
Кояш сибә иде нурларын.
Шул вакытта минем тынычлыкны,
Йөрәгемне син бит урладың.

Йокы качты төнлә әгәр,
Син булмасаң минем янымда.
Йөрәккәем озаккамы түзәр,
Шашып, ташып күпме ул тибәр?

Яз гына гаепле микән,
Минем яратуыма.
Сәбәп кенә булгандыр ул,
Сөюнең кайтуына.

## Гадилек

Кешелекле тирән гадилек,
Соклandыра мине бүген дә.
Онытылып барган шушы хисне,
Күреп булмый бик күп кешедә.

Бик кызганыч, нигә алыштырдык,
Чын йөрәктән чыккан сүзләрне.
Байлык, акча барсын хәл итә диеп,
Алдашабыз, алдап күпләрне.

Мамонтларда җирдә калмадылар,
Чират кемдә хәзер дисәгез.
Кешелеклек бетеп бара диеп,
Әйтәм бүген, гафу итегез.

Сугыш чоры балалары белән,
Чагыштырсам әгәр үземне.
Алар белән аралашкач, анлыйм,
Булган алар бары түземле.

Бер алманы бишкә түгел, йөзгә,
Бүлгән чакларыда күп булган.
Ачлык, ялангачлык күреп үссәләр дә,
Йөзләрендә матур нур калган.

## Акыл

Акыл базарда сатылмый,
Шундый бездә мәкаль бар.
Белем алмаган кешедә,
Уйлау фикере бик тар.

## Ирек кирәк

Ирек кирәк иҗат кешесенә,
Буйсынып ул яши ала алмый.
Богауларда булса әгәр кулы,
Иҗат итә ала ул алмый.

Ирек булса баскычсыз да була,
Айга таба үрне алырга.
Сулар һаваларны чиста итеп,
Дөньяларда яшәп калырга.

Ялгыз бүре кебек яшәргә дә,
Мөмкин бездә иҗат кешесе.
Үз фикере аның һәрвакытта,
Аңлый аны бары үз ишесе.

Ирек булса иҗат кешесенә,
Кирәк түгел байлык һәм мөлкәт.
Каләме һәм дәфтәрләре булса,
Вак-төяккә дә хәтта канәгать.

## Затлы пар

Тормыш итәр өчен кирәк,
Парыңның иң затлысы.
Аның белән гомер буе,
Бар бит әле атлыйсы.

## Розалар

Җәйләр җиткәч бакчаларда,
Розаларны үстерәм.
Аларның тәмле исенә,
Көн саен мин “исерәм”.

Кызыл, матур розаларны,
Бүләккә сиңа бирәм.
Үземне синең янында,
Бәхетле итеп күрәм.

Минем өчен алар сиңа,
Әйтер яратам диеп.
Минем яныма чыгарсың,
Кызылдан күлмәк киеп.

Розаларның энәләре,
Бәхетебезне саклар.
Яратып, сөеп яшәрбез,
Кермәсләр үтеп ятлар!

## Раббым бүләге

Безнең очрашулар,
Раббым бүләге.
Синең өстеңдә,
Ак туй күлмәге.
Кунаклар килгән,
Безне котларга.
Насыйп ит Раббым,
Бергә атларга.
Безнең арага,
Ятлар кермәсен.

Җилләр исмәсен,
Сөю китмәсен.
Бүгеннән башлап,
Без икәү бергә.
Бәхетләр яусын,
Гаиләбезгә.
Син минем өчен,
Тугансың җиргә.
Беренче көннән,
Гашыйк мин сиңа!

## Чит кеше

Бик чит кеше,
Якын булыр өчен.
Яратсаң да,
Җитмәс синең көчең.

Бик чит кеше,
Гаилә корыр өчен.
Белми хәттә,
Ни теләвен үзен.

Бик чит кеше,
Якынаймас еллар үтсә дә.
Бик чит кеше,
Шуның өчен күңел үртәлә.

## Салкын мәхәббәт

Мәхәббәтең инде сөендерми,
Җылы учак кебек җылытмый.
Сүнәм, сүнәм диеп ул пыскылдый,
Рәхмәт әле ярый елатмый.

Мәхәббәтең инде салкынайды,
Ерактан ук сизәм боз исен.
Җанга үтә аның салкынлыгы,
Бозга катты мәхәббәт хисем.

Әйдә барын өр яңадан башлап,
Тормыш итеп карыйбыз дисең.
Бозга каткан йөрәгемне эретергә,
Җитәр микән соң синең көчең?

Мәхәббәтең инде сөендерми,
Төннәремдә төш булып керми.
Искә төшсә бергә булган чаклар,
Бозлы йөрәгемне тик тырный.

Җир белән күк кебек,
Без бергә синең белән.
Сөюемне, назларымны иркәм,
Мин сиңа бирмәм бүтән.

## Әче, әче

Әче, әче, әче диеп,
Туйларда кычкырмагыз.
Яшьләргә тормышларында,
Бәхет бары теләгез.

Әче, әче, әче диеп,
Туйларда кычкырмагыз.
Яшь парларның сөюләрен,
Шик астына куймагыз.

Әче түгел, татлы булсын,
Сөйгәннәрнең тормышы.
Бернигәдә карамастан,
Нинди һава торышы.

Әче, әче, әче диеп,
Төшермәгез гел искә.
Кияү тырыш, уңган, булган,
Килен әйтерсең чәчкә.

## Соң

Бер беребезне ишетергә,
Никтер язмаган безгә.
Ишекләр ябылып куйды,
Без хәзер түгел бергә.

Бер беребезне күрергә,
Интегеп без яшәдек.
Горурлык безне җиңде шул,
Ялгышлар без эшләдек.

Бер беребезне сөяргә,
Никтер насыйп булмады.
Ялгызлар булып калдык без,
Кемнәр безне бутады.

Бер-беребезне гафу итеп,
Бергә яшәргә иде.
Ләкин никтер безнең хисләр,
Ярты юлда киселде.

Бергә яшәп, бергә булып,
Сөеп яшәргә иде.
Вакытлар узалар бик тиз,
Безгә хәзер соң инде.

## Мәхәббәттә яшим дисәң

Күп тапкырлар ялгыштым мин,
Сөюне таптым диеп,
Еллар үтте, үтте яшьлек,
Мәхәббәтемне көтеп.

Мәхәббәттә яшим дисәң,
“Сукыр” булуың кулай.
Күпне күрсәң яратмыйлар,
Дөресе менә шулай.

Мәхәббәтне саклыйм дисәң,
“Ишетмәскә” дә кирәк.
Бер сүз әйтсәң сиңа җавап,
Яратмыйсың син димәк.

Байлыкны күреп бик күпләр,
Җанын сата шайтанга.
Ә соңыннан ниләр күргән,
Чыгып сөйли мәйданга.

## Чиле пешле мәхәббәт

Чиле пешле сөюләрең белән,
Аптыратып йөрмәсәң икән.
Яратам диеп әйтә алмавыңа,
Кемнәр генә гаепле иркәм.

Яратам диеп әйтү өчен,
Кирәк хиснең булуы.
Гаилә корганда кирәк,
Мәхәббәтнең парлы булуы.

Йөрәгемне тартып алдың да,
Мине җансыз калдырдың.
Йөрәксез соң ничек яшәргә,
Сөеклем диеп кемгә дәшәргә?

Чиле пешле сөюеңнең,
Көтәм әле пешкәнен.
Аңлый алмыйм әгәр китсәм,
Синнән башка ниләр эшләрмен.

Юкка гына көтмәгәнмен икән,
Сөюемнең пешеп җиткәнен.
Мин бәхетле бүген, улым үсә,
Мин аны бик озак көткәнмен.

## Кеше белән кешеләрчә

Бөек үрләргә ирешсәң,
Борыныңны күтәрмә.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Мөмкин кире төшәргә.

Кешеләрчә кеше белән,
Аралашырга өйрән.
Онытма син, гомер алда,
Тормыш күле ул тирән.

Мөмкин түгел, алай диеп,
Ашыкма син әйтергә.
Аллаһ кына барсын белә,
Ниләр буласын күрә.

Шушы матур дөньяларда,
Булма кардәшләргә чит.
Масаймыйча, тигез генә,
Яшәвеңне дәвам ит!

## Кеше түзә

Кеше түзә, барысына да түзә,
Түземлекнең чиген үтсә дә.
Күңелендә аның ышаныч бар,
Елап күз яшьләре бетсә дә.

Кеше түзә, ләкин түземлекнең,
Күпме була чиген үтәргә?
Шул вакытта көчле “шартлау” була,
Әйтерсең лә давыл күтәрә.

Кеше түзә, ләкин йөрәгендә,
Төзәлмәслек аның яралар.
Бик тиз алар арабыздан китә,
Ялгыз кала ник “сөйгән” ярлар?

Кеше түзә, ләкин түземлекнең,
Күпме тора икән бәясе?
Түзә, түзә яшьлек үтеп киткәч,
Килми никтер бүтән түзәсе.

## Сулар һавам чиста!

Очрадың син минем юлымда,
Гомеремнең матур чагында.
Бик яшь үзең, чибәр, сөйкемле,
Гади шундый минем шикелле.

Күзләреңә карап туя алмыйм,
Иртән, кичен гел сине уйлыйм.
Бергә булган чаклар кадерле,
Төннәр якты, көннәрем ямьле.

Сулар һавам чиста һәм иркен,
Минеке син булырсың иркәм.
Йөрәгемдә сине мин йөртәм,
Күрешүне сагынып бик көтәм!

Истә калган барлык мизгелләр,
Юлыбызда чәчәк һәм гөлләр.
Җылы, аяз, матур ул көннәр,
Йолдызлы күк һәм айлы төннәр!

## Сине бәхетле итү!

Миңа язган икән, миңа,
Бәхетле сине итү.
Кирәк булган икән озак,
Шуңадыр сине көтү.

Йөрәк көтә иде сине,
Белгән кебек күптәннән.
Очып чыгар кебек иде,
Сине кочып үпкәннән.

Көттем сине мин язларын,
Көттем сине җәйләрен.
Эзләдем, озак эзләдем,
Күрешүнең җайларын.

Тормыш матур, яшәү рәхәт,
Булса янда сөйгәннәр.
Истә минем синең белән,
Төне буе йөргәннәр.

Миңа язган икән, миңа,
Сине бәхетле итү.
Кирәк булган икән озак,
Шуңадыр сине көтү.

## Минем белән шаярма!

Шаярып син миңа,
Яратам димә.
Сөйгәнеңне сизеп,
Яшисем килә.

Шаярып син миңа,
Килеп кагылма.
Янымда син гел бул,
Тик соңга калма.

Шаярып син миңа,
Китәм диеп әйтмә.
Китсәң әгәр дә син,
Көт мине димә!

Шаярма сөям диеп,
Алдама үзеңне.
Бары берне ярат,
Ач син күзеңне!

## Күрмим кояш нурларын

Күрмим мин кояш нурларын,
Синең белән булмагач.
Үсми күңел, чәчәк атмый,
Әйтерсең мин алмагач.

Көннәр бик озак үтәләр,
Син янымда булмагач.
Вакыт табып минем якка,
Килеп чык син бушагач.

Вакыт юк диеп сәбәп тапма,
Бәхетне безнең сакла.
Күтәрмен мин күпме кирәк,
Минем ышанычны акла.

Мин сине яратам диеп,
Килеп мине кочакла.
Йөрәк җылымны тоярсың,
Минем кайнар кочакта.

## Кадерле идең!

Син минем өчен,
Кадерле идең.
Ялган белән тулы,
Булган тик сүзең.

Син минем өчен,
Әле дә кадерле.
Белмәдең бары син,
Минем кадерне.

Син минем өчен,
Иң якын идең.
Синең янына мин,
Көн саен килдем.

Син минем өчен,
Тугансың диден.
Вакыт үтү белән,
Үзгәрдең үзең.

## Мин сине яратам!

Мин сине яратам,
Ә син мине юк.
Нигә шулай икән,
Синең җавап юк.

Салкын иреннәр,
Яшьләнгән күзләр.
Сөю беткәнгә,
Үткән күп көннәр.

Үзең яраткан,
Сине яратмый.
Син яратмаган,
Күңелгә ятмый.

Ташып ага хисләр,
Юк тик сөеклем.
Хыялымда син бар,
Шуңа сөенәм.

Бергә булмассыз диеп,
Белеп әйтәләр.
Безнең арабызда,
Биек киртәләр.

## Ир-ат бәхете

Сөйгәнең янында булса,
Карап торса күзеңә.
Ул-кызларың килеп кочып,
Килеп кунса тезеңә.

Нинди бәхет әткәң-әнкәң,
Улым диеп эндәшсә.
Татулыкны безнең күреп,
Бик байлар да көнләшсә.

Ир-атның бәхете хатын,
Бәхете балалары.
Мәшакатьләр дә сизелми,
Вак-төяк калганнары.

Ир-ат бәхете,
Уңсаң хатыннан.
Егылып төшмәсәң,
Тормыш атыннан.

Хатыннарның да,
Була төрлесе.
Аналарының,
Алар көзгесе.

Рәхмәт сиңа сөйгән ярым,
Булганга минем белән.
Көнем якты, кәефем шәп,
Чөнки яратуыңны беләм!

## Теләсәң!

Бик, бик теләсәң,
Сөю эзләсәң.
Табарга мөмкин,
Өмет өзмәсәң.

Бик, бик теләсәң,
Гаилә корырга.
Сөеклең белән,
Мәңге булырга.

Син теләп кенә,
Бәхет ул килми.
Син күрәчәкне,
Беркем дә күрми.

Насыйп итмәсен,
Раббым ялгызлык.
Без парлар диеп,
Ник без ялгыштык?

**Туры әйткән өчен ачуланма!**

Ачуланма туры итеп әйткән өчен,
Мәхәббәтем югалтмасын бары көчен.
Матур итеп каршы алыйк иртәләрне,
Ашыгып без кайтыйк өйгә эштән кичен.

Гашыйк булган кеше генә,
Аңлар мине.
Ә бүтәннәр көлеп әйтер:
Исәр син диеп, яки тиле.

Бу хисләрне бернигә дә алыштырмам,
Сөеклемне яратамын һәм дә сөям.
Яннарымда булмаса ул,
Кара кисәү булып көям.

Туры әйткән беркайчан да,
Сатмас сезне.
Гайбәт сатып, күп сөйләшмәс,
Ул аз сүзле.

## Каршы алыйк!

Ачу, үпкәләрне куеп,
Барсын Иске елларга.
Каршы алыйк Яна елны,
Бар да безнең кулларда.

Яна елны каршы алыйк,
Бәхет, шатлыклар теләп.
Син мина туганым кебек,
Мин дә булырмын терәк.

Дуслар булып, татулыкта,
Аралашыйк дускаем.
Син минем язым, кояшым,
Кичләр җиткәч син аем!

## Әйтә алмам

Яратам диеп әйтә алмам бүтән,
Истә калган синең ташлап киткән.
Кайтарырга теләсәм дә кире барсын,
Моның хәзер кирәге бар микән?

Яратам диеп әйтә алмам бүтән,
Җиргә төштем күктән мин дә күптән.
Барысын да оныттым мин иркәм,
Истә никтер сине беренче кат үпкән.

Яратам диеп әйтә алмам бүтән,
Сөюнең дә вакыты бар икән.
Барысы да үткән, күптән үткән,
Улыбыз да үсеп инде җиткән.

Яратам диеп әйтмәм сиңа бүтән,
Кадере ул яратуның беткән.
Саф мәхәббәт, сөю, назлар безнең,
Ни өчендер җилгә очып киткән.

## Башка сыймас...

Кеше башына сыймаслык,
Бик күп хәлләр бар икән.
Адәм баласы боларга,
Ничекләр түзә микән?

Җавапсыз сөю дисеңме,
Хыянәт һәм башкалар.
Көндә нидер булып тора,
Тыныч түгел башкайлар.

Бәхетемне таптым дигәч,
Беркөн ялгыз каласың.
Ни өчен Раббым, ни өчен,
Шулай үчләр аласың?
Кеше башы түзә икән,
Йөрәкләре дә түзә.
Кара чәчләр дә агара,
Тормыш ул шулай изә.

Ә шулай да бу дөньяда,
Яшәүләре бик рәхәт.
Якты дөньяга килгәнгә,
Әти-әнигә рәхмәт!

## Гаепле үзем!

Синең шундый булуыңа,
Үзем гаепле.
Яба алмадым йөрәгемдә,
Сиңа ишекне.

Мәхәббәттән сукыр иде,
Шул минем күзем.
Әле генә аңлап алдым,
Калгач бер үзем.

Үз-үземә ничә тапкыр,
Сорау бирдем мин.
Алда сине ниләр көтә,
Кем белән соң син?

Бу сорауга җавап тапмый,
Мин бик күп йөрдем.
Җавап тапмый кача-кача,
Ерак йөгердем.

Синең шундый булуыңа,
Үзем гаепле.
Яба алмадым йөрәгемдә,
Сиңа ишекне...

## Туган көн!

Владимир Мироваев,
Шатлык безгә өләшә.
Гармуннары белән дә ул,
“Син” диеп тик сөйләшә.

Бик оста уйный гармунда,
Сәхнә бары уенда.
Безнең бәхеткәдер шуңа,
Туган ул кыш аенда.

“Менә” дигән гаиләсе,
“Күз тия” тик күрмәсен.
Уңышлары күккә менеп,
Югарыга үрләсен.

Туган көнең белән котлап,
Озын гомер телибез.
Сәхнәгә чыгып уйнасаң,
Яшәр татар телебез.

Мондый татарлар булганда,
Куркытмыйлар бураннар.
Милләтләрне берләштерә,
Алар уңган, булганнар!

Зурлап, басып
алкышлыйбыз,
Бөек, талант иясен.
Ижатыңны яратабыз,
Йөзгә кадәр яшә син,
Чөнки безгә кирәк син!

## Үземне бүләк итәм

Матур көнне бүләк итәм сиңа,
Бүләк итәм кояш нурларын.
Бер күрүдә сиңа гашыйк булдым,
Тынычлыкны минем урладың.

Матур төнне бүләк итәм сиңа,
Бүләк итәм якты йолдызлар.
Төн үтүгә сизәм үзгәрешләр,
Эределәр күнелдәге бозлар.

Матур гөлләр бүләк итәм сиңа,
Гөлләр кебек матур үзеңдә.
Яшь сабыйдай сөенәм мин әгәр,
Шатлык күрсәм синең йөзеңдә.

Үземне дә сиңа бүләк итәм,
Бүләк итәм сиңа хисемне.
Очрашуны сагынып мин көтәм,
Очып сиңа иркәм тагын киләм.

## Очраштырды тормыш

Очраштырды тормыш тагын бер,
Әйтте миңа-ни югалттың, күр.
Күрдем шулчак чибәр бер кызны,
Бик сөйкемле кап-кара күзле.

Бу күзләргә кереп чумарлык,
Бер елмайса мине егар күк.
Әйдә тагын гел бергә булыйк,
Ялгызлыктан инде без туйдык.

Еллар аша мәхәббәт артты,
Сөеклем миңа әйләнеп кайтты.
Безне күреп болытлар качты,
Җәйге төннәрдә йолдызлар атты.

Тормыш өйрәтте, бергә булырга,
Бары бергә без бик тә бәхетле.
Кадерен беләм, сөям, сөеләм,
Язмыштан узмыш юк шул, юк диям.

## Яхшы парлар идегез

Хыянәтең ачылмады бүген,
Сөенечтән яна күзләрең.
Болыт яба синең йөзләреңне,
Ялган синең барлык сүзләрең.

Антлар биреп кушылган идегез,
Пар балдаклар беркөн кидегез.
Сокландык без сезнең матурлыкка,
Бик бәхетле сез пар идегез.

Үтте бары биш, алты ел вакыт,
Арагызда биек киртәләр.
Сөендерми сезне айлы кичләр,
Сөендерми язгы иртәләр.

Үз парыңны кемгә алыштырдың,
Дөрес юлдан нигә тайпылдың?
Биш минутлы хискә син бирелеп,
Төзәлмәслек ялгышлык кылдың.

Хыянәтең бүген ачылмады,
Озакламый ләкин ачылыр.
Үкенечкә калыр барысы да,
Бәхет капкалары ябылыр.

## Кырыс булма безгә

Коронавирус, коронавирус,
Булма безгә бик кырыс.
“Мойте чаще руки”- диеп,
Әйтте безгә бер урыс.

Магазин киштәләрендә,
Калмады бер нәрсәдә.
Кырып алып бетерделәр,
Акча юк кесәләрдә.

Ике, өч тапкыр чит илгә,
Чыга иде бик байлар.
Миллиардларын алар хәзер,
Кайда илтеп куярлар?

Читтән торып кына хәзер,
Эшлибез без эшләрдә.
Өйдәге азыклар бетсә,
Ниләр икән эшләргә?

Фашистны җиңгән милләткә,
Вирус түгел бер нәрсә.
Җиңү көнендә очрашырбыз,
Куллар, аяклар йөрсә!

## Бозлы йөрәк

Синең бозлы йөрәгеңне,
Эретергә тырыштым.
Парым бул диеп сиңа килдем,
Уйлап син диеп тормышым.

Иртән, кичен, көндә сиңа,
Бәхет бары теләдем.
Сине бәхетле итәм диеп,
Бик зур бәя түләдем.

Салкын, бозлы карашларың,
Өшетте йөрәгемне.
Аякларым атламады,
Бармакларым йөрмәде.

## Йөрәк кушканча

Мин сине яраттым,
Йөрәк кушканча.
Сиңа кирәк булды,
Бары тик акча.

Мин сине яраттым,
Булганча көчем.
Аңлый алмыйм хәзер,
Сөйдем ни өчен?

Мин сине яраттым,
Кышын һәм язын.
Мин сине яраттым,
Җәен һәм көзен.

Мин сине яраттым,
Диеп гомергә.
Саубуллашмый киттең,
Түгел без бергә.

## Яратуыңны белдем

Гомер буе синең,
Йөрәгеңдә яшәрмен.
Онытырга теләсәң дә,
Иртән, кичен дәшәрмен.

Гомер буе синең,
Чыгармын юлларыңа.
Күрмәмешкә салышсаң да,
Мин синең уйларыңда.

Гомер буе синең,
Хыялыңда калырмын.
Тормыш сынауларын үтеп,
Үз юлымнан барырмын.

Гомер буе сине сөеп,
Гомер көзенә килдем.
Гафу сорап килмәсәңдә,
Яратуыңны белдем.

## Үзгәртергә була теләсәң

Исән чакта була барысын үзгәртергә,
Гонахларың булса гафу үтенергә.
Беренче адым яса син үзең,
Ачылыр шулчак синең чын йөзең.

Беренче адым ясавы авыр,
Көчлеләр бары таба ул җаен.
Исеңә төшер бергә чакларны,
Үткәргән идек авылда җәен.

Бергә чакларны баштан үткәрәм,
Ялгыштык ахры, шунысы әрәм.
Кирәкми миңа читләр бәхете,
Юк, юк кирәкми булмасын хәрәм.

Үземнеке дә җиткән, бик җиткән,
Сине көтеп күп вакыт үткән.
Бергә булырга язмаган икән,
Ни өчен шулай әйтче син иркәм.

Юл бирергә беркем теләмәде,
Хаклымы син әллә гаепле?
Бездән тормый хәзер бернәрсә дә,
Эзләмә син булмас гаепне!

## Чәй эчәбез

Тәмле итеп чәй эчәбез,
Матур үтә көнебез.
Баш авыртмый чәй эчкәннән,
Арта бары көчебез.

Сөтләп, тәмләп чәй эчәбез,
Шуңа күрә көчле без.
Чәй янына чыга бәлеш,
Әле мичтән чыккан килеш.

Бәлештән соң чират җитә,
Татлы, баллы чәк- чәккә.
Мәтрүшкәле чәйләр эчү,
Сихәт бирә йөрәккә.

Кайнар чәйне эчүләре,
Күңелгә җылы бирә.
Чәй эчеп алган арада,
Мичтә ашта өлгерә.

Чәй генә эчеп алырга,
Утырышкан идек без.
Туганнар белән сизелми,
Матур үтте көнебез.

Нигъмәте нидән гыйбәрәт,
Безнең татар чәенең.
Самовары кайнап тора,
Ямьләп өйнең ул түрен.

Туганлыкның кадерләрен,
Ныгытабыз без шулай.
Татар ашларын ашавы,
Авыр түгел ул болай.

Туганнар белән аралар,
Бер дә ерагаймасын.
Кунакларга гына йөреп,
Яшәргә безгә язсын!

## Бер адым да артка чигенмәскә

Безне җиңү мөмкин түгел,
Дошманнар торсын белеп.
Тезләндерә алмас алар безне,
Беләбез без үлә дә “көлеп”.

Бер адым да артка чигенмәскә,
Өйрәттеләр безне бабайлар.
Бөек җиңүләрдә җиңеп кайткан,
Күршедәге батыр агайлар.

Кыю итеп үстерергә иде,
Узебезнең балаларны да.
Безгә каршы дошман күтәрелсә,
Җиңеләчәк алар барысы да.

Күп кан түгеп безгә җиңү килде,
Күпме гомерләрне ул алды.
Тынычлыкны без дә саклап калыйк,
Ветераннар бик сирәк калды.

## Яңа ел

Яңа елны көтә күңел,
Кыш Бабайга әле ышана.
Аклык, сафлык алып килсен,
Давылсыз гына җилләре иссен.

Иске елның "бураннары",
Артта тизрәк калсыннар.
Балалар һәм туганнар тик,
Сау сәламәт булсыннар.

Сезне бары киләчәктә,
Уңышлар, муллык көтсен.
Авырлыклар килгән булса,
Тизрәк үтеп китсен.

Кышлардан соң язлар көтсен безне,
Сөю урап үтмәсен сезне.
Карлар яусын, булсын бураны да,
Тиң ярың тик булсын янында.

Үз ярыңнан Ходай аермасын,
Мул итеп бәхетне бирсен.
Парлыларга сөеп яшәү язсын,
Ялгызлар да үз парын тапсын!

## Мәхәббәткә һәйкәл куяр идем…

Мәхәббәткә тугры булып,
Яшәп җирдә карагыз.
Гайбәтләргә урын булмас,
Тату булыр арагыз.

Мәхәббәткә рәхмәт әйтеп,
Парлап гомер итегез.
Тормыш юлларында абынмыйча,
Алтын туйга килеп җитегез.

Мәхәббәткә һәйкәл куяр идем,
Килсә әгәр минем көчемнән.
Мәхәббәттә тугры булып калдым,
Рәхмәт әйтәм шуның өчен мин.

Мәхәббәттән туган балаларга,
Тәрбия һәм белем бирегез.
Туган телне алар онытмасын,
Бәхет бары шунда, белегез!

## Үтә икән

Барысы да үтеп китә икән,
Үтә яшьлек, үтә картлык та.
Җиргә ак кар кебек, чиста булып,
Сабыйлар туа, безнең шатлыкка.

Барысы да үтеп китә икән,
Үтә көзе, үтә кышы да.
Язлар килә, яшәү алып килә,
Минем күзем күрше кызында.

Барысы да үтеп китә икән,
Үтә ялган, үтә хыянәт.
Нинди җавап бирер идең икән,
Килеп җитсә сиңа кыямәт?

Барысы да үтеп китә икән,
Үтми бары йөрәк ярасы.
Кешеләргә бер ышаныч бетсә,
Йөзләренә килми карыйсы.

## Ара ерак

Син еракта, әмма минем белән,
Тоям синең хәттә тынынны.
Йөрәк тибә, чаба сиңа таба,
Бозып өйдә булган тынлыкны.

Син еракта, әмма минем өчен,
Синнән кадерлерәк кешем юк.
Сөйләшсәк тә бары телефоннан,
Тартып тора син яшәгән як.

Син еракта, килә алмыйм сиңа,
Сизәм ләкин хушбуй исеңне.
Күрешик диеп әйтә алмасам да,
Кабатлыйм еш синең исемеңне.

Син еракта, нәрсә соң ул ара?
Сизсәң әгәр сөю, назларны.
Кичләр җиткү белән һәр көн саен,
Искә алам бергә чакларны.

Мин еракта, әмма синең белән,
Каршы алам бергә таңымны.
Йөрәккәем син диеп тик тибә,
Таптым инде әллә тиңемне?

## Синең шәүләң

Синең шәүләң минем арттан килә,
Тыныч яшәү бирми ул, нигә?
Барда инде үтте, онытылды,
Әллә күңелең миңа омтылды?

Синең шәүләң минем арттан килә,
Ни өчен ул шаяра, көлә?
Синең миңа булган хисләреңне,
Бәлки аның яңартасы килә?

Синең шәүләң минем арттан килә,
Яратканны ул минем белә.
Соң шул инде, бергә булыр өчен,
Яратырга сине юк көчем.

Синең шәүләң минем арттан килә,
Куып тотачагын ул белә.
Ни өчен соң шулай, барда үткәч,
Сөюең тагын яңарып килә?

## Оныт мине

Оныт мине,
Мин бөтенләй булмагандай.
Барысы да элеккечә булыр димә,
Оныт мине, булмас алай.

Гафу ит диеп, миннән сорама,
Ходай гафу итәр.
Ялганыңнан синең туйдым,
Миңа булды, җитәр.

Үзең өздең араларны,
Хәзер инде мөмкин түгел.
Төзәтергә яраларны, оныт мине,
Минем синдә түгел күңел.

Хыянәтне гафу итү,
Булыр иде артка китү.
Мин оныттым сине,
Синдә оныт мине, оныт мине.

Көтмәгәндә, берни булмаганда,
Хыянәтең синең ачылды.
Шушы көннән башлап,
Йөрәгем минем сиңа ябылды.

Оныт мине, оныт мине,
Мин бөтенләй булмагандай.
Оныт мине, оныт мине,
Гафу итсен безне Ходай...

## Син минеке түгел инде

Мин сөйгәндә кайда идең үзең,
Кайда булды синең күңелең?
Бик күп еллар үтсәләр дә нигә,
Болыт белән ябык күңелең?

Мин сөйгәндә ниләр уйладың син?
Сөюемне күрә белмәдең.
Чит сүзләргә никтер ышандың син,
Минем белән сөю бүлмәдең.

Мин сөйгәндә ни өчендер күрми,
Китә идең минем сөюне.
Әйтерсең лә ишетми идең син,
Яратам мин сине диюемне.

Миннән киткәч бәхетле булдыңмы?
Яктырдымы синең көннәрең?
Әллә инде барда элеккечә,
Ялган белән үтә төннәрең?

Ничек кенә булса да белеп тор,
Бәхет кылә сиңа телисе.
Минем өчен син ят кеше күптән,
Баламның син бары әнисе.

## Искә алам

Карлар күмеп китте сөюемне,
Кышкы салкын, карлы көннәрдә.
Искә алам һаман сине генә,
Кышкы озын, йокысыз төннәрдә.

Искә алам синең күзләреңне,
Искә алам синең йөзеңне.
Искә алам синең сүзләреңне,
Өзә алар минем үзәгемне.

Ходай шулай язган киләчәкне,
Алдан белеп булмый күрәчәкне.
Туганда ук язылып куелган,
Гомерләрдә ниләр күрәчәкне.

Көтәм әле язлар җиткәнен,
Күмгән карлар эреп беткәнен.
Умырзая кебек кар астыннан,
Чыгар кебек минем сөйгәнем.

Искә төшә синең күзләрең,
Искә төшә синең йөзләрең.
Искә төшә синең сүзләрең,
Сизә микән синең йөрәгең?

## Минем белән кал

Яратулар, яз көннәре кебек,
Матур, җылы булып башлана.
Әмма тормыш мәшәкате белән,
Сөйгәннәр бер-берсенә "ташлана".

Яратулар, җәй көннәре кебек,
Бик тиз генә үтеп китә ул.
Гомерлеккә бергә дигән идек,
Ни өчендер без бергә түгел?

Яратулар, көз көннәре кебек,
Үзәкләргә үтә ул...
Сөйгән кешеләр кай вакыт,
Салкынаеп китә шул.

Яратулар, кыш көннәре кебек,
Җанны өшетеп үтә ул.
Шул өшүдән исән калса йөрәк,
Гомерлеккә сызлап үтә ул.

Яратуны саклап калу өчен,
Өстәлләрдә булып торсын бал.
Кышкы салкыннарда чәй эчкәндә,
Син матурым, минем белән кал.

Яратулар никтер китә үтеп,
Ә "ярасы" кала озакка.
Яратырга иде шулай итеп,
"Бикләп" барысын олы йозакка.

## Җылы сүз көтә йөрәк

Барыбыз да мохтаҗ без җылыга,
Мохтаҗ назга, мохтаҗ сөюгә.
Бик күп чакта бер җылы сүз җитә,
Шул сүзләрне йөрәк бик көтә.

Күп кирәкми, бер-ике сүз җитә,
Җылытырга бозлы күңелне.
Уйлар үзгәрәләр, башта сорау туа,
Ул ярата мине түгелме?

Тормыш мәшәкате белән бик күп чакта,
Онытыла безнең якыннар.
Яратам диеп бары әйтү җитә,
Кабына тагын кайнар ялкыннар.

Ак-карадан тора безнең тормыш,
Бик куп чакта була “бураннар”.
Куркытмыйлар алар әгәр янда булса,
Бердән-берең синең, туганнар!

## Текәләр...

Текәләрнеңдә текәсен,
Тормыш куя урынга.
Шигыремнең бу юллары,
Шул кешеләр турында.

Ашыгалар әйтерсең лә,
Күккә менәселәре бар.
Кагыйдәләрне бозалар,
Аларга юллар бик тар.

Берәү генә булган җитми,
Кирәк тагын бер, икәү.
Шөкерне әйтә белмиләр,
Нәпсе кирәк ди- дүртәү.

Урыннарына утыргач,
Карарга да кызганыч.
Гыйбрәт булсын калганнарга,
Шундый аяныч тормыш.

Тормыш шулай барыбызны,
Иртәме, соңмы тигезли.
Дәлилләп барсын аңлата,
Үзенекен ул эшли!

## Ата белән анасыннан күчкән

Нинди йөзле булыр иде микән,
"Битлекләрен" әгәр салсалар.
Безнең янда, безнең арабызда,
Яшиләр бит шундый бәндәләр.

Кулларыннан бер эш барып чыкмас,
Ялган белән яши тик алар.
Чөнки ата-анасыннан күчкән,
Күреп шуны бары ул үскән.

Диннән алар бик еракта тора,
Курыкмыйлар хәттә Ходайдан.
Гомерләрен Раббым алачагын,
Белмиләр шул, әллә бер айдан.

Талап ала алар кешенекен,
Күзгә карап ялган сөйлиләр.
Үзләрен тик бары яраталар,
Бер кешене алар сөймиләр.

## Кара алтын хакына

Туган ягым Татарстан,
Бик бай кара алтынга.
Нефтьчеләр көн-төн эшли,
Күмеп илне алтынга.

Татарстан чәчәк ата,
“Кара алтын” хакына.
Яңа йортлар, юллар калка,
Татарстан халкына.

Рәсәй эчендә беренче,
Син урнәк башкаларга.
Кунаклар синнән өзелми,
Агылы башкалага.

Аермалы башкалардан,
Башкалабыз безнең Казан.
Бигрәкләр дә инде матур,
Ишетелә көн дә азан.

Кол Шәриф манаралары,
Бик ерактан күренә.
Имам әйткән азаннары,
Күңелгә үтеп керә.

Гади бер авыл баласы,
Нефть таба утыз ел.
Белгән догаларын укый,
Теләп сезгә изге юл!

## Исән чакта

Исән чакта кадереңне,
Белүчеләр булсачы.
Үтенеп сорыйм, зинһар өчен,
Тормыш булма син ачы.

Исән чакта син яхшы диеп,
Әйтүчеләр табылса.
Нинди бәхет кояш чыкса,
Төнлә йолдыз атылса.

Исән чакта эшне күреп,
Әгәр мактап алсалар.
Гомерлеккә истә калыр,
Шундый мизгелләр алар.

Исән чакта борчуларсыз,
Яшәп алырга иде.
Шушы юлларны укыгач,
Никтер күзгә яшь килде.

## Әниемне сагынам

Иманлы бул балам диеп,
Әни мине үстерде.
Назлы, йомшак кулы белән,
Башларымнан сыпырды.

Гыйбадәт кылып Раббыма,
Көн дә килеп сыенам.
Авырлыклар китә үтеп,
Тик әниемне сагынам.

Аллаһ Тәгаләдән куркып,
Гонахларда кылмадым.
Гайбәтләрдән ерак тордым,
Гаделлекне яраттым.

Белмичә кылган гонахлар,
Булса Раббым гафу ит.
Өммәтебез гомерендә,
Озак яшәү насыйп ит.

Гыйбадәт кылып Аллаһка,
Башымны түбән иям.
Намазларны көндә укып,
Тәүбә-истигъфар кылам.

Ислам дине бик тә күркәм,
Ислам дине бик гүзәл.
Мәчетләрдә сәждә кылып,
Җомгадан кайтып киләм.

Изгелекләр гел кылырга,
Насыйп булсын, и, Раббым.
Бары синең белән бергә,
Яшәү көче мин таптым!

## Картлык бар кешегә бирелми

Бар кешегә яшьлек бирелсә дә,
Картлык бар кешегә бирелми.
Тормыш безгә бер генә бирелә,
Гомер, яшәү ике бирелми.

Ничек яшәсәң дә гомер үтә,
Кара чәчләргә дә чал кертә.
Җыерчыклар үткән еллар эзе булып,
Йөзләргә дә үзгәреш кертә.

Бер кешегә язмыш мәрхәмәтле була,
Икенчегә биктә бик кырыс.
Бирешмичә күрәчәгеңне күреп,
Тик яшәргә иптәш син тырыш.

Яшьлегеңдә ни син чәчсәң шуны,
Картлыгыңда җыеп алырсың.
Балаларыңа тәрбия һәм белем бирсәң,
Шул балалар белән калырсың.

Һәр мизгелнең үз яхшы ягы бар,
Барысы кирәк яшәү дәверендә.
Яшьлектә ул булса саф мәхәббәт,
Зирәклек килә картлык көнендә.

Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый,
Яшәү еллар белән саналмый.
Үзеңнән соң калдыра алсаң яхшы эшләр,
Алар мәңгелек, алар онытылмый!

## Халык белән

Мин халыктан ерак түгел,
Шуңа күпчак тула күңел.
Күрсәм әгәр фәкыйрьләрне,
Күрсәм әгәр гарипләрне.

Бик бай илдә яшибез без,
Ләкин ярлы ник халкыбыз?
Эшләсәк тә көн төн әгәр,
Эшебезгә юк хакыбыз.

Бик тә түзем халык бездә,
Ышана ул буш сүзгә дә.
Яхшы заман килер диеп,
Эшли әле башын иеп.

Булыр микән моның чиге,
Әллә инде яман чирме?
Йөз буынга байлык туплау,
Мәңгелек мин диеп уйлау.

Мин халкымнан ерак түгел,
Саулык телим аңа бүген.
Тыныч булсын тормыш күгең,
Ачылсын тик синең күзең!

## Нефть таба

Нефть таба минем әтием,
Көн-төн эшли булсын диеп өем.
Тырыша ул, улым өчен диеп,
Алга бара максатлар куеп.

Нефть таба минем әтием,
Авыр эше, түземлек телим.
Нефтьчеләр алар чын ирләр,
Телим тагын мин бөек үрләр!

Нефть таба минем әтием,
Кара алтын таба, алтын таба.
Җир астында ничә еллар,
Елга булып нефть ага.

Нефть таба минем әтием,
Көтеп алам эштән кайтуын.
Улым диеп кочаклап ала,
Шуңа да мин бәхетле бала!

## Вакыт үтте димә

Яшьлегем син мине ташлап китмә,
Ямьле көннәр миңа бүләк ит.
Йөзләремнең нуры сүрелмәсен,
Йөрәккәем минем бик яшь бит.

Яшьлегем син мине ташлап китмә,
Бергә безгә яхшы иде бит.
Булды сиңа, вакыт үтте димә,
Гонахларым булса гафу ит.

Бергә шулай яшик әле тагын,
Күрдек бергә карасын, агын.
Иртә миңа танышырга картлык белән,
Йөрәгемдә юк аңа урын.

Яшьлеккәем рәхмәт барысы өчен,
Җәлләмәдең, бирдең яшәү көчен.
Күз алдында узган ул көннәр,
Шул чак тула никтер күңелләр.
(Алар минем таштан түгелләр.)

## Кунак кына без бу җирдә

Мәхәббәттән генә бары,
Дөньяга туа бала.
Шушы мизгелдән соң гына,
Гаилә тулы була.

Бала туа бу дөньяга,
Бәхетле булыр өчен.
Ата-ана назы алып,
Чын кеше булыр өчен.

Кеше туа бу дөньяга,
Нәсел калдырыр өчен.
Балалар табып үстереп,
Оныклар күрер өчен.

Кеше туа бу дөньяга,
Калдырыр өчен эзен.
Күпме изгелекләр кылган,
Чутларга була күзен.

Кеше туа бу дөньяга,
Бик озак яшәрмен диеп.
Бакыйлыкка китеп бара,
Бар мөлкәтен калдырып.

Кунак кына без бу җирдә,
Онытмыйк туганнар.
Аңласыннар иде шуны,
Бездән соң да калганнар!

## Көтмәгәндә

Сөю килде башны әйләндереп,
Көтмәгәндә, тигез урында.
Язам бүген шушы матур жырны,
Гүзәл, чибәр бер кыз турында.

Бер карашы тора нинди бәя?
Бер елмайса әсир итәрлек.
Җиңел атлаулары, йөрүләре, эх,
Бер сүз әйтсә эреп китәрлек.

Тыңлый белә, бүлми ярты юлда,
Аның белән бәхет минем алда.
Чәчәк бәйләмнәре бүләк итәм,
Минем бәхет бары синең кулда.

Очрашуны зарыгып мин көтәм,
Мәхәббәт бар сизәм карашыннан.
Матурымны йөрәгемдә йөртәм,
Рәхмәт сиңа булганыңа иркәм!

## Яшьлек үтеп бара

Бик кызганыч, яшьлек үтеп бара,
Күзгә юллар алда күренә.
Атла ашыкмыйча, бирешмә ди(е)п,
Яздым йөрәгемнең түренә.

Билет алып булса яшьлегемә,
Кайтып килер идем тагын мин.
Бәясенә карап тормас идем,
Чөнки яшьлегемне сагындым.

Күз йомганчы үтеп китте яшьлек,
Бары йөрәк әле яшь кебек.
Балалар да җитте безне куып,
Тик каласы килә яшь булып.

Ике түгел, бер бирелә гомер,
Кадерен белеп яшәргә өлгер.
Үкенмичә яшә, атла горур,
Картлыкта да көннәр бик матур!

## Ялкын булган чакта

Күзләремдә ялкын булган чакта,
Сөюемне күрә белмәдең.
Салкын иде синең карашларың,
Төшләремә шуңа кермәдең.

Мин яратам диеп әйткән чакта,
Чит ятларга карый идең син.
Йокыларсыз үтте күпме төннәр,
Борчуымны күрми идең син.

Күпме кеше эзли сөйгән ярын,
Таба ала алмый, кызганыч.
Минем мәхәббәтне таптап киттең,
Шунысы бары мина аяныч.

Күзләремдә ялкын булган чакта,
Сөюемне сизә алмадың.
Минем белән булмасаң да бел син,
Сиңа бары бәхет теләдем!

## Бәхет өчен кирәк...

Бер кешегә бәхет өчен кирәк,
Йортның бай һәм матур булуы.
Икенчегә бәхет өчен җитә,
Янда булса үзенең сылуы.

Бер кешегә изге эшләр өчен,
Тәүлектәге җитми вакытлар.
Икенчесе өчен вакыт үтми,
Уйлар өчен безнең вакыт бар.

Кайберәүләр шөкер диеп әйтә,
Булганына аз-маз өендә.
Ә күпләргә миллионнар да җитми,
Кыска гына вакыт гомерендә.

Тормышымны җырга күмеп,
Яшәргә мин тырышам.
Күнелемә рәхәт була,
Кешеләргә булышсам.

## Туган якның кырлары

Туган якның кырларына карап,
Күпме шигырь һәм җыр язылган.
Шул кырларга күпме игенченең,
Хезмәте һәм көче салынган.

Язлар җиткәч уҗым басулары,
Яшеллеккә елда күмелә.
Икмәк булып көзен җитешкәнче,
Күпме тирләр җиргә түгелә.

Көзен алар дулкын, дулкын булып,
Тибрәнәләр җылы җилләрдә.
Уңыш яхшы булып, артып калса,
Китә хәттә чит илләргә дә.

Икмәк үстерү серләрен,
Белә бары игенче.
Көнне төнгә ялгап эшли,
Охшый аңа җир эше.

## Үзгәртергә тырышып карадым

Үзгәртергә диеп дөньяны мин,
Тырышып та инде карадым.
Үзгәрешне үземнән мин башлап,
Кырынмый да иртән башладым.

Мода диләр, сакал һәм мыекны,
Яше, карты йөри сакаллы.
Кайберәүләр кырыналар көндә,
Мина калса алар акыллы.

Чиста, пөхтә йөрүләре авыр,
Күпләр уйлый, артык мәшәкать.
Килешә алмыйм андыйлар белән мин,
Керсез һәм пакъ булсам, кәнәгать.

Минем өчен түгел сакал, мыек,
Яратам мин йөрергә аек.
Ничек булмый яшәп бу дөньяда,
Кеше исеменә булыйк без лаек!

## Минем өчен

Ул минем өчен,
Ул минем көчем.
Көтеп алам мин,
Көннең һәр кичен.
Назга күмелеп,
Үтә кичебез.
Бергә булганда,
Биктә көчле без.
Яшисе килә,
Сөеп сөелеп.

Яхшы хәбәрләр,
Килсен өелеп.
Бергә булырга,
Язсын гел бергә.
Таңнар атканын,
Карарга бергә.
Ул минем аем,
Кояшлы маем.
Күрәсем килә,
Аны көн саен!

## Яхшылык һәм яманлык

һәркөн саен безне көтә,
Яхшылык һәм яманлык.
Кеше кайсын сайлап ала,
Акыл җиңә яки наданлык.

Яманлык кылсаң җавабын,
Тотарсың берәр вакыт.
Җавап бирәселәр булыр,
Раббым каршына басып.

Яхшылыктан, яхшылыкны,
Эзләргә кирәк түгел.
Яхшылык эшлә дә оныт,
Никтер куша шулай күңел.

Мәңгелекне уйлап яшә,
Матур фани дөньяда.
Оҗмахларга керер өчен,
Ал син алдан юллама.
(Бары тик соңга калма!)

## Тәрәз төбе

Әниемнең тәрәз төбе,
Гөлләргә бик бай иде.
Яраннарның бик күп төрен,
Ул күршеләргә бирде.

Балаларын яраткандай,
Назлап үстерә иде.
Уңган куллы булгангамы,
Гөлләр гел чәчәк бирде.

Тормышын чәчәккә күмеп,
Тыйнак булып яшәде.
Без тук, бөтен булсын диеп,
Төнлә йон җегерләде.

Безне башта тукландыра,
Чәй эчерә иде ул.
Сигез балага ничек соң,
Җитешкәндер ике кул?

Хәзер өч баласы булса,
Ана герой диябез.
Сабыт саба, керне дә без,
Машинага өябез.

Тормышлардан зарланырга,
Бүген урын юк безгә.
Сугыш чоры балалары-
Яшегез җитсен йөзгә!
Сокланабыз без сезгә!

## Ашыкма син, ашыкма

Ашыкма син үпкәләргә,
Искә ал син үткәннәрне.
Оныттыңмы? Искә төшер,
Минем назлап үпкәннәрне.

Вәгъдә биргән көннәр истә,
Күрешкәннәр, һәрбер кичтә.
Чишмә буе, куе таллар,
Онытылмас алар һичтә.

Чын йөрәктән чыккан сүзләр,
Мәхәббәттән янган күзләр.
Онытырга мөмкинме соң?
Барысы да синең өчен!

Син минем гомер юлдашым,
Син минем бәхет кошым.
Болытлы, яңгырлы көндә,
Якты нурым, кояшым!

## Лайк булса кирәк түгел...

Лайк булса бүтән нәрсә,
Безгә кирәкми.
Мәшәкатьләр төшкә кереп,
Безне йөдәтми.
Сорау туса гугл кılә,
Безгә ярдәмгә.
Балаларга интернет һәм урам,
Тәрбия бирә.
Тормышларга безне элек,
Әти- әни өйрәтте.
Хәзер исә Алиса бар,
Кирәкләребез бетте.
Дөнья куа ата-ана,
Балаларга вакыт юк.
Чипсы белән бургер ашап,
Тамаклары була тук.
Хайп ясый бүген яшьләр,
Тигез урында.
Камыр кебек күбертәләр,
Инстаграм челтәрендә.
Лайк куярга онытма,
Шигыремнең астына.
Лаек диеп син уйласаң,
Охшый диеп яз гына.

## Килер шундый вакыт

Шундый вакыт килер тагын,
Кызлар элеккечә яратыр.
Матди байлыкларга карамыйча,
Яшьләр мәхәббәтен аңлатыр.

Шундый вакыт килер, элеккечә,
Төннәр үтәр чишмә янында.
Учак ягып төнне үткәрүләр,
Текә тауның уң як ярында.

Шундый вакыт килер, ышанам мин,
Мөмкин түгел булу бүтәнчә.
Мәхәббәтне сатып алып булмый,
Сою булыр йөрәк кушканча.

Чәчәк бәйләмнәрен бүләк итеп,
Сөюләрен егет аңлатыр.
Никахлашып, парлар туй ясарлар,
Матур булып иртән таң атыр.

Шундый вакыт килер, телим шуны,
Аерылулар булмас, Иншаллах.
Балалар да үсәр тулы гаиләдә,
Хөрмәт, сабырлык булыр һәр өйдә!

## 175...

Унберенче майның иртәсендә,
Балаларның гомере өзелде...
Туктап калды сәгать каллары да,
Бер минутта бар(ы)да киселде...

Нинди генә сүзләр әйтергә дә,
Белеп булмый шундый көннәрдә.
Җаны булган һәр кешедә кайгы,
Язгы матур, җылы көннәрдә.

Яшәргә дә, яшәргә иде бит,
Сабыйларга матур дөньяда...
Әти- әниләре ничек түзәр???
Йомылдылар, мәңгегә күзләр...

Бетте, бүтән юк минем сүзләр...
Яшьләнделәр, туганнар, күзләр...

## Күтеп үтте

Ак аттагы кияүләрне көтеп,
Үтеп китте матур яшьлегең.
Әзер хәзер гаилә син корырга,
Сорамыйча кияүнең яшен.

Аягыңа карап юрганыңны,
Сузарга да өйрәндең үзең.
Тик син ялгыз, парсыз бу дөньяда,
Ялкын белән тулмаган күзең.

Мәхәббәтне сатып алып булмый,
Була бары аны сакларга.
Бик авыр эш, әмма башкарырдай,
Түземлегә бәхет бирә Ходай.

Җиңел тапкан бәхет, бәхет түгел,
Очрашканда тула никтер күңел.
Хушлашканда килми ник китәсе,
Теләгем сине бәхетле итәсе.

## Артык ирек бирдек түгелме?

Бу дөньяда яхшы кешеләр күп,
Яманнар да җирдә җитәрлек.
Яшь буынга артык ирек биреп,
Ялгышлар без эшләп җибәрдек.

СССРда туып үскәнгәме,
Таныш түгел ятсыз гамәлләр.
Бик күпләргә сорау бирер идем,
Ни(э)шләдегез җирдә адәмнәр?

Тора бараниләр булачагын,
Уйларга да бүген куркыныч.
Яхшы якка үзгәртергә кирәк,
Дөньябызны, бу безнең бурыч.

Яхшы кешеләрне очратсам мин,
Сөенечтән тула күңелем.
Ышанып мин калам, киләчәк бар,
Чәчәк атар Иншаллаһ, илем!

## Миннән яхшы

Миннән яхшыны син күп күзләдең,
Бураннар күмеп китте эзләрен.
Уйга калдыңмы? Ниләр эшләдем?
Шуңадыр күрәм, ябык йөзләрең.

Миннән яхшыны син күп эзләдең,
Таба алмадың, талды күзләрең.
Булды бик авыр, ләкин он(ы)тылды,
Исемдә калды ялган сүзләрең.

Миннән яхшыны син озак көттең,
Үз бәхетеңне таптап син киттең.
Табармын диеп, син өмет иттең,
Күктән җирләргә соң шул син төштең.

Миннән яхшылар бардыр, әлбәттә,
Байдыр ул бәлки, яки әйбәттә.
Ләкин соң инде, алар чит ярлар,
Ачы сынаулар безне өйрәтә.
(Ялгызлык шулай тиз килеп җитә).

## Тормыш театр

Барысы да элеккечә,
Тормышта бара кичә.
Монда бар(ы)сыда артистлар,
Гомер ул олы сәхнә.

Барысы да элеккечә,
Кеше туа һәм үлә.
Үлгәннәрнең байлыкларын,
Туганнары тиз бүлә.

Барысы да элеккечә,
Бик күпләр һаман эчә.
Эчмичә калган булсалар,
Заяга үткән кичә.
Барысы да элеккечә,
Бөтен дөнья театр.
Ялгышларсыз яши алсак,
Кад(е)ребез бәлки артыр.

Дөреслекне элеккечә,
Күпләр бездә яратмый.
Кемне, ничек алдасак та,
Төннәрен таннар атмый.
Алдашу безгә ятмый!

## Соңгы кыңгырау

Килеп җитте көткән вакыт,
Соңгы кыңгырау.
Нинди һөнәрне сайларга,
Башта мең сорау.

Олы юлга аяк басу,
Җиңел эш түгел.
Мәктәптән китәсе килми,
Ник тула күңел?

Бер сыйныфта тату булып,
Укыдык бергә.
Яраткан укытучылар,
Рәхмәтләр Сезгә!

Төпле белем бирдегез Сез,
Апа - абыйлар.
Аңлый идек, авыр Сезгә,
Без шук сабыйлар.

Күптә үтмәс таралышып,
Читкә китәрбез.
Ихтисатчы, я нефтьче,
Эшен эшләрбез.

Горур булып, бары алга,
Исәп барырга.
Яхшы эшләргә урнашып,
Тормыш корырга.

Соңгы кыңгырау, чыңла әле,
Бөтен дөньяга.
Ишетелсен, истә калсын,
Шушы тантана!

## Китеп баралар

Әкрен генә китеп баралар,
Сыйныфташлар һәм
авылдашлар,
Безнең арадан.
Иске фотоларны
күзләгәндә,
Күңел сызлый,
Шундый ярадан.
Ун ел бергә,
Укыган идек без,
Авылымның
мәктәпләрендә.
Уку беткәч,
Таралышып беттек,
Рәсәйнең зур
шәһәрләрендә.
Авылда да калучылар
булды,
Кайда туган, шунда яраган.
Җир эшендә эшләп,
Гомер итеп.
Авыр эшләр эшләп,
танылган.
Ожмахларда булсын
урыныгыз,
Диеп кенә кала әйтәсе.
Кичкә караганда әйбәтерәк,
Гомерләрнең һәрбер
иртәсе!

## Ишекләрем ачык, килегез!

Саубуллашу көне килеп җитсә,
Нинди сүзләр әйтер идегез.
Туганнарның йөзләренә карап,
Әйтер идең: нигә килдегез?

Күз алдыннан үтеп китәр иде,
Бер минутта, узган бар гомер.
Вакыт табып килгән туганнарның,
Булганына Аллам бик шөкер.

Кунак кына кеше бу дөньяда,
Туа, укый, эшли һәм китә.
Үзе белән бер нәрсәдә алмый,
Ике метр булган җир җитә.

Саубуллашу көне килеп җитсә,
Нинди сүзләр әйтер идегез?
Уйланырга әле вакытлар бар,
Хәлләремне минем белегез!
Ишекләрем ачык, килегез!

## Ниләр булыр әни?

Ниләр булыр әни, минем белән,
Әгәр син булмасаң янымда?
Йөргән сәгатьләр дә туктап калыр,
Әгәр син булмасаң янымда.

Ниләр булыр әни, минем белән,
Әгәр син булмасаң янымда?
Җылы калмас, әрнү бары булыр,
Туктыйм, туктыйм дигән җанымда.

Ниләр булыр әни, минем белән,
Әгәр син булмасаң янымда?
Авыр чакта, тыным кысылганда,
Синең төсне күрәм улымда.

Ниләр булыр әни, минем белән,
Әгәр син булмасаң янымда?
Көнгә мең кат рәхмәтемне әйтәм,
Шулай булыр җаным барында!

## Синең матурлык

Синең матурлыктан,
Көзге ватылды.
Көндез йолдызлар,
Хәттә атылды.

Синең матурлыктан,
Кошлар көнләште.
Алар бүләк итеп,
Җырлар өләште.

Синең матурлыктан,
Җилләр истеләр.
Тыныч, якты көннәр,
Шаулап киттеләр.

Синең матурлыктан,
Тын калды йөрәк.
Миңа син янымда,
Булуың кирәк!

## Хәлең ничек?

Яхшы булса,
Көнләшерләр...
Начар булса,
Яман сүзләр өстәп,
Тирә якка,
Өләшерләр.
Көнләшерләр...
Тешеңне кыс,
Ишетмә син,
Ул сүзләрне.
Горур атла,
Алга таба.
Ышанма син,
Ул сүзләргә.
Карама да,
Ул күзләргә.
Кала бары,
Тик түзәргә.
Бик түзәргә!
Алар белән,
Араларны,
Тиз өзәргә...
Хәлең ничек?
Диеп әгәр сорасалар.
Бер сүз белән,
Шөкер диген.
Уйга алар,
Тик калсыннар.
Уйлансыннар!

## Ашыкма!

Авырлыклар башларыңа килеп төшсә,
Яшьләреңне күрсәтергә бердә ашыкма.
Сөенерләр кайберәүләр, сине күреп,
Килеп җиткән диеп нинди тормышка.

Күңелләрең тулып, әйтер сүзләреңне,
Әйтәселәр килгән чагында.
Уйла мең кат, ниләр әйтәсеңне,
Чыгарма син тышка барында.

Ак булса да, кара диеп әйтер,
Танышларың булса яныңда.
Шул сүзләрне әйткәч, исеңдә тот,
Укенүләр калыр җаныңда.

Авырлыклар үтеп китәр беркөн,
Барысы да җайга салыныр.
Ләкин кайберләрнең ялган сүзе,
Хәтереңдә уелып калыныр.

## Адымнар

«Адымнар», үткән адымнар,
Алар ничә чакрымнар?
Синдә алган белемнәрем,
Киләчәктә чагылырлар!

## Тыныч тормыш...

Бик бәхетле мин,
Бүгенге көндә.*
Тыныч тормыш,
Муллык өемдә.
Ирештең соң ничек,
Бу тормышка? – дисәң,
Дога кылдым,
Җомга көнендә.
Вәгазьләрне имам укыганда,
Тын алмыйча,
Аны тыңладым.
Рамазан аеның,
Беренче көненнән алып,
Ураза да тота башладым.**
Динле кеше,
Денсез була алмый,
Яман эшләр хәттә уйда юк,
Саулыктан тик,
Аерма син Раббым,
Эшләр өчен җирдә яхшылык!

**Күзләр генә тия күрмәсен!*

** *Аллаһ Тәгаләнең ризалыгы өчен*

## Саташкан дөнья

Хәерле иртә,
Саташкан дөнья.
Сиңа карап ник,
Калдым мин уйга.

Чаба кешеләр,
Ким түгел аттан,
Әйтерсең әллә,
Куалар арттан.

Хәерле көн,
Адашкан дөнья.
Иртән Мәскәүдә,
Кичек син кайда?

Кеше куа ди(е)п,
Син дә куасың.
Бугаздан безне,
Ник син буасың?

Хәерле кичләр,
Кешеләр нишләр?
Нәпсе кирәк ди,
Ялсыз ул эшләр.

Тыныч яшәргә,
Мөмкин түгелме?
Төрле очкычлар,
Баскан күгеңне.

Дөнья куабыз,
Шушы заманда.
Беләсе килә,
Ниләр бар алда?

## Сабан туй

Кайтып киләм сабан туйга,
Туган авылга.
Көрәшләрдә бил алышып,
Батыр калырга.

Сабан туе берләштерә,
Ел саен безне.
Күрешүгә сәбәп була,
Ача күзебезне.

Нинди матур туган яклар,
Гүзәл кешеләр.
Шәһәрдә таба алмаган,
Үзең ишеләр.

Җирдә эшләгән кешегә,
Әйтик рәхмәтне.
Туган якта калган кеше,
Бик тә бәхетле.

Яшәгәннәр бары читтә,
Мине аңларлар.
Авылда хәттә икенче,
Аталар таңнар!

## Сине түгел, бүтәнне

Сине түгел бүтәнне мин,
Кочамын бүген.
Әммә ләкин синең кебек,
Ул инде түгел.

Яратам диеп әйтәм аңа,
Булсын күңеле.
Йөрәк бары тыныч түгел,
Сөюнең үз иле.

Алдаулары үз- үзеңне,
Мөмкин түгелдер.
Искә төшкәч, күпме яшьләр,
Тагын түгелер?

Ни өчен соң саклап булмый,
Чын мәхәббәтне?
Эзлибез ник чит ятларны,
Бай һәм әйбәтне?

Сине түгел бүтәнне мин,
Кочамын бүген.
Синдә, миндә бәлки моңа,
Гаепле түгел.

## Онытыла чынбарлык

Хыялланып күп вакытта,
Онытыла чынбарлык.
Табылырмы икән көчләр,
Барсын жиңеп чыгарлык.

Хыялларга чумып яшим,
Яшь булмаса да яшем.
Кайларда икән сөеклем,
Минем яраткан кешем?

Очратканмын икән имеш,
Үземнең сөйгән ярны.
Йөрәккәем кайный, яна,
Эретер хәтта карны.

Кешегә көч бирә хыял,
Йөрәккә ята, әйтерсең бал.
Хыялдагы гүзәл затым,
Мәңге минем белән кал.

Чынбарлыкта барысы да,
Хыялдагы кебектер.
Ләкин тирә- якларымда,
Юк шул синең кебекләр.

## Гомер китабы

Гомер китабының битләренә,
Безнең яхшылыклар язылыр.
Яман эшләр була калса әгәр,
Авыр эзләр алар калдырыр...

## Көчле татар

Урыслашып беттек милләттәшем,
“Почему?”- ди(е)п миннән сорама.
Оныкларың: “Деда”- диеп дәшсә,
Өмет белән алга карама.

“Деда”- дигәч, “Внучок”- диеп синдә,
Әйтәчәксең җавап биргәндә,
Кайда булдың ул кечкенә чакта,
Үрмәләп ул әле йөргәндә?

Урыслашып беттек милләттәшем,
Сиңа бүген уян диеп дәшәм.
Шундый матур татар телебезне,
Алыштырмыйк әйдә, кардәшем!

Тәрбияне бирә алмадың син,
Бүген әле шат һәм көләсең.
Татарга бит элек электән үк,
Толмач кирәк түгел, беләсең.

О “кей”- диеп әле кыстырабыз,
Әйтер сүзләр беткән диярсең.
Без ТАТАР- диеп өйрәт балаларны,
Шул чакта син көчне сизәрсең!

## Кызу ярыш

Берсеннән берсе уздырып,
Ярыша депутатлар.
Сайлау узып киткәч никтер,
Барысын оныталар.

Мине сайлагыз мине диеп,
Вәгъдәләр күп бирәләр.
Депутат булып сайлангач,
Буш сүз сөйли түрәләр.

Ничек булырга кирәген,
Күпләре сөйли безгә.
Ничек кирәген беләбез,
Эшләргә кирәк сезгә.

Ел башыннан бәяләрне,
Күтәрергә кирәкми.
Картларны күрәм шуңа тик,
Йөрәгем бары әрни!

Ярты пенсия акчасын,
ЖКХга бирәләр.
Калган яртысын ничектер,
Тагын йөзгә бүләләр.

Рәхмәт сезгә өлкәннәр,
Авыр тормыш көткәннәр.
Сезнең алдагы бурычны,
Кайчан түләрбез икән?
Түли алырбыз микән?

## Таҗлы вирус

Таҗлы вирус үтеп керде,
Һәрбер өйнең түренә.
Чебен кебек вак-төяктә,
Зур фил булып күренә.

**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**

Рәвил Фәйзи улы Шибаев
Равиль Файзиевич Шибаев

# УЛ минем өчен,
# УЛ минем көчем!

Шигырьләр

---

**Сборники стихотворений Шибаева Р.Ф. не могут быть воспроизведены, тиражированы и распространены без разрешения автора.**